**Татарстан Республикасы**

**Арча муниципаль районының**
**Арча шәһәр муниципаль берәмлеге**
**Арча шәһәр Советы**
**422000, Арча ш. Совет майданы, 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

**Муниципальное образование**
**город Арск**
**Арского муниципального района**
**Республики Татарстан**
**Совет города Арск**
**422000,г. Арск, площадь Советская , 27**
**тел. 3-16-25, 3-12-35**

# КАРАР

**« 13 » гыйнвар 2023 ел** **№ 1**

**Арча шәһәр Советының 2012 елның 29 ноябрендәге 58 номерлы карары белән (01.11.2016, №48, 02.03.2018 № 83, 11.05.2021 №37 үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында Арча шәһәр Советы карары проекты буенча гавами тыңлаулар билгеләү хакында**

"Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы "Арча шәһәре" муниципаль берәмлеге Уставы, Арча шәһәр Советының 2022 елның 17 августындагы 73 номерлы карары белән расланган "Арча шәһәре" муниципаль берәмлегендә гавами тыңлаулар (җәмәгать фикер алышулары) оештыру һәм үткәрү тәртибе турындагы Нигезләмә нигезендә, халыкның шәһәр җирлегенең муниципаль хокукый актлар проектлары буенча фикер алышуда катнашуга хокукын тәэмин итү максатыннан карар бирәм:

1. Арча шәһәр Советының 2012 елның 29 ноябрендәге 58 номерлы карары белән (01.11.2016 N 48, 02.03.2018 № 83, 11.05.2021 №37 үзгәрешләр белән) расланган Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карары проекты буенча гавами тыңлауларны 2023 елның 24 февраленә билгеләргә.

2. Арча шәһәр Советының 2012 елның 29 ноябрендәге 58 номерлы карары белән (01.11.2016 N 48, 02.3.2018 № 83, 11.05.2021 №37 үзгәрешләр белән) расланган Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында Арча шәһәр Советы карары проекты буенча гавами

тыңлауларны 17.00 сәгатьтә ТР, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт адресы буенча уздырырга.

3. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә карата тәкъдим ителгән үзгәрешләр буенча гражданнарның тәкъдимнәрен, кисәтүләрен һәм гавами тыңлауларда катнашуга гаризаларын язмача рәвештә 2023 ел, 24 февраль көненең 17.00 сәгатенә кадәр Татарстан Республикасы, Арча шәһәре, Совет мәйданы, 27 йорт адресы буенча җибәрәләр, дип билгеләргә. телефон 8(84366) 3-16-25.

4. Әлеге карарны һәм Арча шәһәр Советының Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Арча шәһәре» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында карары проектын Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru), Арча муниципаль районы рәсми сайтында «Район җирлекләре» бүлегендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Арча шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе Р.Ф. Касыймовка йөкләргә.

«Арча шәһәре» муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Арча шәһәр Советы рәисе И.Г. Нуриев